ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
Кутузова ул., дом1,
город Лениногорск, 423250

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Кутузов урамы, 1нче йорт,
Лениногорск шәһәре, 423250

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е КАРАР

2024 елның «05» сентябре № 1202

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2021 елның 16 декабрендәге 1180 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында «Федераль законның 2 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 8 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2021 елның 16 декабрендәге 1180 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында»2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын

эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары белән» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021елның 16 декабрендәге 1180 номерлы карары белән расланган Өстәмә гомуми белем бирү программаларын, шулай ук Спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәреш кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 3.8 бүлек белән тулыландырырга:

«3.8. Балигъ булмаганның законлы вәкиле тарафыннан балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алу

3.8.1. Балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен мөрәҗәгать итүче булып торучы балигъ булмаганның законлы вәкиле алганда, балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең кәгазь чыганактагы документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләрен алу хокукын гамәлгә ашыру мөрәҗәгать итүче булмаган балигъ булмаганның законлы вәкиле тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин. Бу очракта балигъ булмаганның законлы вәкиле булган мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта балигъ булмаганның балигъ булмаганга карата тиешле хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алуга вәкаләтле башка законлы вәкиленең шәхесен таныклаучы документ турында белешмәләрне күрсәтә.

3.8.2. Балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең кәгазь чыганактагы документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләре, әгәр мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең сорала торган нәтиҗәләрен шәхсән үзе алырга теләк белдергән булса, балигъ булмаганның башка законлы вәкиленә күрсәтелми.

3.8.3. Балигъ булмаганга карата кәгазьдә язылган документ рәвешендә рәсмиләштерелгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен, шул исәптән аларны бирү ысуллары һәм сроклары, мөрәҗәгать итүче булмаган балигъ булмаганның законлы вәкиленә күрсәтү тәртибе, әлеге бүлекнең 3.8.2 пунктында каралган таләпне исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен билгели торган норматив хокукый актлар белән билгеләнә.».

3. Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 16 декабрендәге 1180 номерлы карары белән расланган каникул вакытында балаларның ялын оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәреш кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 3.8 бүлек өстәргә:

«3.8. Балигъ булмаганның законлы вәкиле тарафыннан балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алу

3.8.1. Балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен мөрәҗәгать итүче булып торучы балигъ булмаганның законлы вәкиле алганда, балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең кәгазь чыганактагы документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләрен алу хокукын гамәлгә ашыру мөрәҗәгать итүче булмаган балигъ булмаганның законлы вәкиле тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин. Бу очракта балигъ булмаганның законлы вәкиле булган мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта балигъ булмаганның балигъ булмаганга карата тиешле хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алуга вәкаләтле башка законлы вәкиленең шәхесен таныклаучы документ турында белешмәләрне күрсәтә.

3.8.2. Балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең кәгазь чыганактагы документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләре, әгәр мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең сорала торган нәтиҗәләрен шәхсән үзе алырга теләк белдергән булса, балигъ булмаганның башка законлы вәкиленә күрсәтелми.

3.8.3. Балигъ булмаганга карата кәгазьдә язылган документ рәвешендә рәсмиләштерелгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен, шул исәптән аларны бирү ысуллары һәм сроклары, мөрәҗәгать итүче булмаган балигъ булмаганның законлы вәкиленә күрсәтү тәртибе, әлеге бүлекнең 3.8.2 пунктында каралган таләпне исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен билгели торган норматив хокукый актлар белән билгеләнә.».

4. Әлеге карарны рәсми публикаторда - «Лениногорские вести» газетасында бастырып чыгарырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче З.Г. Михайлова

Л.М.Галимова
5-17-41